КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 7 сентябрь г.Казань № б-1980

Татарстан Республикасы халкын авыл хуҗалыгы продукциясе һәм көндәлек кирәкле азык-төлек товарлары белән тәэмин итү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2024 елның 14 сентябреннән 29 декабренә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары тарафыннан махсус билгеләнгән территорияләрдә авыл хуҗалыгы продукциясен һәм көндәлек кулланыштагы азык-төлек товарларын сату буенча атна саен ярминкәләр (алга таба – ярминкә) үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль районнары башлыклары белән берлектә, ярминкәләр үткәрү урыннарына авыл хуҗалыгы продукциясен һәм көндәлек кулланыштагы азык-төлек товарларын алып килүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

атна саен ярминкәләр үткәрү урыннарын билгеләүне һәм әлеге урыннарда сәүдә итү өчен шартлар тудыруны тәэмин итүне;

ярминкәләр үткәрү урыннарында иҗтимагый иминлекне, җәмәгать тәртибен һәм террорчылыктан сакланышны тәэмин итү өчен, шул исәптән хосусый саклау оешмалары хезмәткәрләрен җәлеп итеп, кирәкле чаралар күрергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә ярминкәләр үткәрү урыннарында терлекчелек продукциясен алып килүне һәм сатуны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына тышкы нарядларны җәмәгать тәртибен һәм гражданнарның иминлеген тәэмин итү өчен ярминкәләр үткәрү урыннарына якынайтырга;

Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә ярминкәләр үткәрү урыннарында азык-төлек продукциясенең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын контрольдә тотуны көчәйтергә.

6. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында ярминкәләр үткәрү барышын яктыртуны тәэмин итәргә.

7. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М.А.Җәббаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин